**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

V чакырылышның  Vутырышы
**КАРАРЫ**

«_07_» июля2026  ел                                    № 21                                    Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район
Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»гы 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында"гы 26.06.2026 № 664 карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының "Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 15.04.2013 ел, № 14 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы Район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05